| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан Зеленодольский муниципальный район Исполнительный комитет Нижневязовского городского поселения** | **Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы Карамалы тау шэһэр жирлеге башкарма комитеты** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Карамалы Тау штп **КАРАР**

**07.11.2022** **№51**

Түбән Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитетының 19.01.2021 №05 карары белән расланган гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (10.09.2020 ред.), Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Түбән Карамалы шәһәр җирлеге башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбән Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитетының 19.01.2021 ел, №05 карары белән расланган гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибенең 3 пунктына үзгәрешләр кертергә, аны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Халык җыены карары белән муниципаль берәмлектә (торак пункт (яисә аның территориясе өлешендә) яшәүчеләрнең гомуми саныннан 30 проценттан артып китә алмаган гражданнарның аерым категорияләре билгеләнә, алар өчен түләүләр күләме кимергә мөмкин.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында: Карамалы Тау штп, Беренче Май ур., 70 йорт, ҖҮИ

административ бинасында мәгълүмат стенды, Карамалы Тау штп, Беренче Май ур., 70 йорт (ҖҮИНЕҢ административ бинасы).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И.В. Паракова